КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 июль г.Казань № 823

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май,

555 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4.2$^{1}$ пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2$^{1}$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә иртә ярдәм хезмәтләрен күрсәтү 6 айга кадәр чорда, иртә ярдәм күрсәтү буенча индивидуаль программаны исәпкә алып, көненә 4 сәгатькә кадәр күләмдә белгеч тарафыннан эшләнгән баланың дәресләрдә булуы буенча индивидуаль график нигезендә гамәлгә ашырыла. Социаль хезмәт күрсәтү срогы балага 4 яшь тулганга кадәр озайтылырга мөмкин.»;

3.4.2$^{2}$ пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2$^{2}$. Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлегендә хезмәтләр күрсәтү 6 айга кадәр чорда, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын исәпкә алып, көненә 4 сәгатькә кадәр күләмдә белгеч тарафыннан эшләнгән баланың дәресләрдә булуы буенча индивидуаль график нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипкә 2$^{1}$ нче кушымтада:

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә социаль хезмәтләрдән файдаланучыга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре» таблицасының 1.1 пунктындагы 5 графасында «көн саен» сүзен төшереп калдырырга;

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә социаль хезмәтләрдән файдаланучының ата-анасына (законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре» таблицасының 1.1 пунктындагы 5 графасында «көн саен» сүзен төшереп калдырырга;

«Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү бүлегендә социаль хезмәтләрдән файдаланучыга, социаль хезмәтләрдән файдаланучының ата-анасына (законлы вәкиленә) кыска сроклы иртә ярдәм хезмәтләре күрсәтү исемнәре, тасвирламасы, күләмнәре» таблицасының 1.1 пунктындагы 5 графасында «көн саен» сүзен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин